| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОКУВАКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ КУАК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

2019 елның 13 марты　　　　　　　　　　№ 11

Татарстан Республикасы “Иске Куак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196нчы "Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында” 2018 елның 24 гыйнварындагы 32нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5 946,47 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә

2. Әлеге карарны Иске Куак авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

«Иске Куак авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы И.Н.Сушкова

1нче кушымта
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Куак” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 11нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында “Иске Куак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе, *сумнарда*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Гробны, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 2 252 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 1 126 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 2 568,47 |
| **Барлыгы** | **5 946,47** |

2нче кушымта
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Иске Куак авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 13 мартындагы 11нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында “Иске Куак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең бәясе** | **Хезмәтләрнең бәясе, *сумнарда*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне каплау | 560 |
| 3. Гробны, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 1 692 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 1 126 |
| 5. Погребение (рытье могил и захоронение) | 2 568,47 |
| **Барлыгы** | **5 946,47** |